| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 14.12.2023 | г. Казань | № 813-206/кс-2023 |

Казан шәһәренең «Карсар» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга 2024 – 2028 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 14.12.2023 № 58-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Билгеләргә:

салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Казан шәһәренең «Карсар» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Карсар» ҖЧҖ) өчен эчәргә яраклы суга, әлеге карарның 1-2 нче кушымталары нигезендә, календарь буенча бүленгән тарифлар;

салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Карсар» ҖЧҖ өчен, әлеге карарның 3 нче кушымтасына туры китереп, эчә торган суга 2024-2028 елларга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын.

2. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Карсар» ҖЧҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә,

чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 № 813-206/кс-2023
карарына 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Карсар» ҖЧҖ өчен эчәргә яраклы суга
2024 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «Карсар» ҖЧҖ | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә)* | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 60,80 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 70,72 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 50,67 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 58,93 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 № 813-206/кс-2023
карарына 2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Карсар» ҖЧҖ өчен эчәргә яраклы суга
2025-2028 елларга* календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «Карсар» ҖЧҖ | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә)** | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 70,06 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 70,06 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 70,06 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 73,56 |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 73,56 |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 73,73 |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 73,73 |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 77,41 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 58,38 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 58,38 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 58,38 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 61,30 |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 61,30 |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 61,44 |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 61,44 |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 64,51 |

* 2025-2028 елларга эчәргә яраклы суга тарифларга ел саен төзәтмәләр кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары нигезендә уздырыла.
** Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2023 № 813-206/кс-2023 карарына 3 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Карсар» ҖЧҖ өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2024-2028 елларга тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе* | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе** | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе*** | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Карсар» ҖЧҖ | | | | | | |
| 1.1 | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге кулланучылары | | | | | | |
| 1.1.1 | Эчәргә яраклы су | 2024 | 576,35 | - | - | - | 1,88 |
| | | 2025 | - | 1 | - | - | 1,88 |
| | | 2026 | - | 1 | - | - | 1,88 |
| | | 2027 | - | 1 | - | - | 1,88 |

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе* | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе** | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе*** | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| | | 2028 | - | 1 | - | - | 1,88 |

* Озак сроклы җайга салуның икенче һәм аннан соңгы елларына операция чыгымнарының база дәрәҗәсе Россия ФТХ 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрнең 45 пунктында каралган формула буенча исәпләнә.
** «Карсар» ҖЧҖ өчен норматив табыш дәрәҗәсе билгеләнми.
*** «Карсар» ҖЧҖ өчен су агызуга тарифка «су югалту дәрәҗәсе» энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткече билгеләнми.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге